

“*Татарча ДАРТС* “

***Максат***: төсләрне, өйрәнгән лексиканы истә калдыру, нинди? соравына аңлап җавап бирергә, сүтезмә ясарга өйрәтү. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү.

***Җиһаз:*** Трапеция формасында киселгән материаллар(кызыл, зәңгәр, яшел, сары, ак, кара, кызгылт сары), “ябышкак” кечкенә туплар; үтәкүренмәле пленкадан киселгән шаблоннар.

**I вариант**

***Уен барышы***:

Балалар “ябышкак” кечкенә тупларны төсләргә аталар. Төсне атыйлар. Шул төскә туры килгән рәсем- шаблонны ябыштырып сүзтезмә ясыйлар. (М-н: яшел кыяр, ак песи)



“***Җөмлә төзе!*** “

***Максат***: балаларны пиктограммалар ярдәмендә җөмләләр төзергә һәм укырга, Нишли? Соравына дөрес җавап бирергә өйрәтү, татар телендә җөмлә төзелеше белән таныштыру. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү.

***Җиһаз:***пиктограммалар төшерелгән карточкалар

***Уен барышы***: **1 вариант:** һәр юлда җөмләдәге сүзләр буталып куелган. Шушы сүзләрдән җөмлә төзергә кирәклеге әйтелә.

**2 вариант:** тәрбияче төрле пиктограммалар куелган квадратлар әзерли. Һәм балаларга ситуация куела: “Нинди җөмләләр яшерелгән?”



“***Өлешләрдән бер бөтенне җый*** “

***Максат***: Бу нәрсә? Нинди? соравына аңлап, дөрес җавап бирергә өйрәтү, татар теленә кызыксыну уяту. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү.

***Җиһаз:***бер бөтен рәсемне өлешләргә бүленгән карточкалар

***Уен барышы***: балалар өлешләргә бүленгән карточкалардан бер бөтен рәсем җыялар һәм тәрбиячене соравына аңлап җавап бирергә тиешләр.



**“Тылсымлы янчык”.**

***Максат***: Төсләрне, саннарны истә калдыру; Нинди? Ничә? Нишли ? Син нишлисең? соравына аңлап җавап бирергә өйрәтү, өйрәнгән лексиканы истә калдыру, пиктограммаларны укып командаларны куллана белү.

***Җиһаз:*** капчык, саннар, хәрәкәтне белдерүче пиктограммалар

***Уен барышы***: Тәрбияче кулында капчык, капчыкта төрле төстәге саннар. Бер бала капчыктан санны ала, атый, төсен әйтә. Шул төстәге түгәрәкләрдән сан буенча бара. Түгәрәкләр өстендә төсле кәгазьләрдән пиктограммалар. Бала шул пиктограмманы ала, укый. Башка балаларга команда бирә.



**“Сана”.**

***Максат***: 10 кадәр саннарны күрә һәм әйтә белергә өйрәтү һәм төсләрне истә калдыру.

***Җиһаз:***“Тылсымлы келәм”, “эзләр” .

***Уен барышы***: Тәрбияче төрле юнәлештә, төрле төстәге түгәрәкләр өстенә саннар язылган эзләр куеп чыга. Бала шул эзләрдән йөреп санны, төсне атарга тиеш була.



***“Курчакны киендер”***

***Максат***: “Күлмәк”, “Чалбар” сүзләрен истә калдыру, “Ки”, “Сал” фигыльләрен әйтергә өйрәтү һәм төсләрне истә калдыру, нинди? соравына аңлап җавап бирергә өйрәтү, өйрәнгән лексиканы истә калдыру.

***Җиһаз:*** яссы-курчаклар(малай, кыз), төрле төстәге күлмәкләр, чалбарлар;

***Уен барышы***: “Курчакка кием сайларга булыш” проблемалы ситуциясе куела. Балалар магазиннан киемнәр сатып алалар. Курчакларны киендерәләр



**<u>Серле открыткада нинди җөмлә яшерелгән»</u>**

**<u>Максат:</u>**балаларны пиктограммалар ярдәмендә җөмләләр төзергә һәм укырга, Нишли? соравына дөрес җавап бирергә өйрәтү. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә кунектерү, татар теленә кызыксыну уяту.

**<u>Уен барышы:</u>**Картоннан күп катлы итеп ябыштырып ясалган квадрат, открытка дүрт тапкыр ачыла. Открытканың 4 ягына, җөмлә килеп чыгарлык итеп пиктограммалар ябыштырылган. Бала открытканы ачып бара һәм пиктограммаларны укып җөмлә төзи.



***“Үз чәчәгеңне тап”***

***Максат***: балаларның татар телендә сөйләм күнекмәләрен ныгыту, сүзлек байлыкларын арттыру, бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү. Мөстәкыйль фикер йөртергә, сорауларга җавап бирергә күнектерү. Татар телендә аралашу теләге үстерү. Бер-берсен тыңлый белү, кызыксанучанлык сыйфатлары тәрбияләү.

***Җиһаз:*** төрле төстәге чәчәкләр, магнитлы тасма беркетелгән “бәйләнгән” бал кортлары, биремнәр.

***Уен барышы***:

**Тәрбияче:** балар, карагыз әле нинди матур алан. Нәрсәләр күрәсез?

**Балалар:** чәчәкләр, бал кортлары.

**Тәрбияче:** балар, әйдәгез бал кортлары булып уйныйбыз.

(***матур көй уйный, балалар бал кортлары булып очып йөриләр***)

**Балалар:**Бал кортлары оча, оча

Чәчәклрне күзәтә

Очып аргач, уйнап туйгач

Шул чәчәктә ял итә.

(***сүзләрне әйтеп бетергәч, һәр “бал корты” чәчәккә куна, магнит белән чәчәкне эләктереп ала. Чәчәкнең артында биремнәр язылган. Бала биремне үти***)

“Гөлчәчәк” 81 нче катнаш балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

«Уен- кызыксыну һәм белемгә омтылу утын кабыза торган очкын ул”
**В.А. Сухомлинский.**

# Уйный, уйный өйрәнәбез

Әзерләде: 1 нче категорияле татар теле тәрбиячесе Галеева Г.Р.

Яр Чаллы
Ноябрь, 2019 ел